СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с. Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Башлыгы КАРАРЫ**

**“ 31” октябрь 2022 ел** **№ 6**

**Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Апаз авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех авылында Хәсәншәех авылы, Космонавтлар урамы, 20 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2022 елның 18 ноябренә 11 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех авылында Хәсәншәех авылы, Космонавтлар урамы, 20 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2022 елның 18 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех авылында Хәсәншәех авылы, Космонавтлар урамы, 20 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2022 елның 18 ноябренә 19 сәгать 00 минутта халык җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Комсомол урамында яшәүчеләр.
2нче этап: Татарстан урамында яшәүчеләр.
3нче этап: Космонавтлар, Пионер урамнарында яшәүчеләр.

5. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2023 елда Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа

инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, түләү күләме 400 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- авылны төзекләндерү өчен җиһазлар сатып алу (бензин чапкычы - 1 данә, бензин чапкычына запас частьләр);
- 1 данә күләмендә янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;
- Хәсәншәех авылында су челтәрләрен ремонтлау;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Хәсәншәех авылының Комсомол урамыннан "Киндер күле" чишмәсенә кадәрге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлын вак таш җәеп тигезләү;
- МТЗ 80 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу (чапкыч);
- Хәсәншәех авылында юл кырыйларын, авышлыкларны грейдер белән тигезләү, урам-юл челтәренең юл өслегеннән пычракны җыештыру?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ""

6. Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Апаз авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Хәсәншәех авылы, Космонавтлар урамы, 20 йорт, Татарстан урамы, 42 йорт, Комсомол урамы 31 йорт адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АПАЗОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ОГРН 1021606156857
СОВЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609003056